| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 сентябрь № 709

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 декабрь, 1061 нче; 2013 ел, 21 май, 335 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1095 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктта:

«югары һөнәри белем бирү учреждениеләре белән» сүзләрен «югары һөнәри белем бирү оешмалары белән» сүзләренә алмаштырырга, «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

2.2 нче пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фәнни кадрларны докторантурада әзерләү, шулай ук фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программаларын үзләштермичә, фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертация әзерләүгә затларны беркетү;»;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«магистратура программалары, фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программалары, һөнәри белем бирү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау

системасында катнашу, шул исәптән система эшчәнлеген фәнни-методик яткан тәэмин итү мәсьәләләре буенча.»;

2.3 нче пунктта:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фәнни кадрларны докторантурада әзерләүне тормышка ашыру, шулай ук фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программаларын үзләштермичә, фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертация әзерләүгә затларны беркетү, гыйльми дәрәҗәләр бирү буенча махсуслаштырылган советлар төзү;»;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«магистратура программалары, фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программалары, һөнәри белем бирү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау программасы кысаларында, үзенең компетенциясе чикләрендә мәгълүмат җыюны һәм аны дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мәдәният тармагында мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органына тапшыруны тормышка ашыру.»;

2.4 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«магистратура программалары, фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программалары, һөнәри белем бирү программалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру, фәнни кадрларны докторантурада әзерләүне тормышка ашыру, шулай ук фәнни-педагогик кадрларны аспирантурада әзерләү программаларын үзләштермичә, фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертация әзерләүгә затларны беркетү;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлгә куючы белән килештерү буенча фәнни-белем бирү үзәкләрен, фәнни-техник үзәкләрне, фәнни һәм технологик материаллардан һәм җиһазлардан күмәк файдалану үзәкләрен, фәнни-мәгълүмати челтәрләрне, мәгълүматлар базаларын һәм банкларын төзүдә катнашу, фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында законнар нигезендә кече инновация предприятиеләрен төзүдә катнашу;»;

3.6.2 нче пунктта «югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «югары һөнәри белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\709.doc